**Контрольно-измерительные материалы**
**для проведения промежуточной аттестации**
**(тестирование)**
**по родному языку (татарскому)**
**(для изучающих татарский язык как родной)**
**10 классы**

## Спецификация работы

### 1. Назначение

Промежуточная аттестация проводится с целью определения уровня освоения обучающимися 10 класса предметного содержания курса «Родной (татарский) язык» в соответствии с требованиями Федерального компонента Государственного стандарта среднего (полного) общего образования, выявления элементов содержания, вызывающих наибольшие затруднения у обучающихся и выявления динамики результативности обучения.

Форма проведения: тестирование, задание с ответом

Время выполнения: 45 минут

### 2. Характеристика структуры и содержания диагностической работы

Работа включает в себя 3 различных задания. При выполнении заданий А1-А16 необходимо выбрать только один из 4 заданных ответов. При выполнении заданий В1-В8 ответы записываются так, как требует задание (цифрами, словами).

### 2. Система оценивания выполнения работы

| % от макс. балла | Оценка |
|---|---|
| 92-100% | “5” |
| 75-91% | “4” |
| 50-74% | “3” |
| Менее 50% | “2” |

**10 кл татар теленнән тест**

**Арадаш аттестация тест биремнәренең А өлеше**
**Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А16) үтәгәндә, дөрес дип табылган җавапны түгәрәк эченә алыгыз**

**А1-А16 биремнәрен эшләгез(тәкъдим ителгән 4 җавап вариантының берсен – дөресен генә сайлап алыгыз)**

**А1. Ирен гармониясе күзәтелгән сүзне билгеләгез:**

***1)эссе; 2)көнне; 3) җылы; 4)капласа.***

**А2.Рәт гармониясенә буйсынган сүзне күрсәтегез.**

**1)табигате; 2)училищеда; 3)гайбәтчән; 4)психология.**

**А3. Саңгырау тартыклар гына булган сүзне билгеләгез:**

**1)халыкның; 2)табигате; 3)кипкәч; 4)инеш.**

**А4. Кайсы рәттә күчерелмә мәгънәле сүз бар?**

**1)Гыйззәтуллин җырлый.**

**2)Күңеле җырлый.**

**3)Бала җырлый.**

**4)Халык җырлый.**

**А5. Синонимнар рәтен билгеләгез.**

**1)эссе, зур; 2) эссе, салкын; 3) эссе, коры; 4 ) эссе, җылы.**

**А6. Бирелгән җөмләдә ясагыч кушымча белән ясалган фигыльне күрсәтегез.**

*Инеш суы кипкәч, халыкның табигате бозыла, кеше үзеннән-үзе холыксызлана.*

*1)***кипкәч; 2)табигате; 3) бозыла; 4)холыксызлана.**

**А7. Билгеләү алмашлыгы кергән җөмләне билгеләгез**.

1) Бәхетнең нәрсә икәнен бәхет үзе узгач аңлыйсың
2) Кояш юк чагында аның яктысын ныграк сагынасың.
3) Зәлифәнең дә әтисе сугышка китә.
4) Ләкин сугыш бу кешенең гомерен өзә: ул Сталинград янында һәлак була.

**А8. Күләм-чама рәвеше кергән җөмләне билгеләгез.**

1)Каюм абзыйның моңлы тавышы бөтен авыл өстенә тарала, мондый көннәрдә инде без малайларга да чын-чынлап бәйрәм була.

2)Ул, мине олыга санап, бик җитди сөйләште.

3) Килеп җитте болыт, шуннан соң коеп салды чиләкләп.

4)Иртәгесен шундый хәбәр билгеле булды: бүреләр авылдагы Ихсан исемле кешенең өч сарыгын буганнар.

**А9. Исемләшкән сыйфат фигыль кергән җөмләне күрсәтегез.**

**1)Гади кеше үз башыннан күпме үткәрә ала, барысын үткәргәнмен.**

**2)Авырып ятучы әбисе янында оныгы бертуктаусыз тегеен-монысын сөйләнә икән.**

**3)Без белгән сулар эчендә моның тикле балыклысы булмаган иде.**

**4)Урманда яшәүчеләрнең тормышын сез белеп бетермәгән кебек, алар да зур шәһәрләрдә яшәүче кешеләрнең ничек яшәүләрен бик аз беләләр.**

**А10. Бирелгән җөмләдән бәйлек сүзне күрсәтегез.**

**Товар вагоннарында тәүлектән артык барганнан соң, Җамалиларны шул куе урманнар янына китереп төшерделәр.**

**1)артык; 2)соң; 3) янына; 4) шул.**

**А11.Бирелгән җөмләдән туры тәмамлыкны табыгыз.**

**Училищеда укый башлагач, Гыйззәтуллин үзенең күзәтүләрен тагын да тирәнәйтте.**

**1)училищеда; 2)Гыйззәтуллин; 3)үзенең; 4)күзәтүләрен.**

**А12. Иярченле кушма җөмләдәге иярчен җөмләнең мәгънә ягыннан төрен билгеләгез.**

**Ул хәзер белә: зур сулы авылның халкы әйбәтрәк холыклы була.**

**1)иярчен ия; 2)иярчен тәмамлык; 3)иярчен сәбәп; 4)иярчен күләм.**

**А13. Күп тезмәле кушма җөмләне күрсәтегез.**

**1)Вагоннар саен дистәләгән кешеләр сибелеп төшеп калгач, йөге җиңеләйгән сыман, поезд җитез генә китеп тә барды.**

**2)Таң әтәчләре кычкырыр алдыннан гына, Әхнәфнең күзләренә йокы эленде.**

**3)Хуҗалары ашыкмагач, атлары да теләр-теләмәс кенә атлыйлар.**

**4)Курку белмәс, тынгысыз малай, әнисе катырак ачуланган саен, трактор тирәсен ныграк ярата барды.**

**А14. Сөйләм сафлыгына зыян китерә торган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.**

1) Алар үзләренең ишек алларына кайтып кергәндә, кич булган, караңгы төшә башлаган иде инде.

2) Кинәт ишек ачылып китте һәм аннан йомшак тавыш белән Абдулланы чакырып алдылар.

3) Йокыдан уянып җитмәгән Казан өстенә әйтерсең үтә күренмәле өрфия каплаганнар.

4) Чисти шәһәр кешесе булгансың!

**А15. Сөйләм төгәллегенә зыян килгән (синтаксик норма сакланмаган) җөмләне күрсәтегез**.

1)Рөстәмнең әтисен бик кечкенә чагында гына күргәне бар.

2)Аның үз гомерендә кешегә түгел, хәтта хайванга да чиерткәне булмады.

3)Җиһангир бу минутта ничек кенә булса да качу ягын карый иде.

4)Син үзең киттең, ә утырткан чәчәкләрең бирӘдә калды.

**А16. [а] авазының о-лаштырылуы: (*ба°ла°лар)*кайсы диалектка хас?**

1) урта диалект;
2) көнбатыш диалект;
3) көнчыгыш диалект;
4) мондый үзенчәлек бер диалектка да хас түгел.

**<u>2 нче өлеш - В өлеше</u>**

**<u>Текстны укыгыз һәм В1-В8 биремнәрен эшләгез</u>**

**<u>(әлеге биремнәрнең җавабын сүзләр яки сүзтезмәләр белән языгыз)</u>**

1) Яз көне булды бу хәл. 2)Яланда йөргәндә, очраган бер кыр чәчәген чокып алдым да, кайтып, тәрәзә төбенә гөл итеп утыртып куйдым. 3)Аның өчен бакчамнан иң яхшы туфракны алып кердем, көн саен диярлек су сибеп тора башладым.

4)Юлда кайтканда шиңә төшкән гөлем тиздән сынын турайтып җибәрде, терелеп, яшәреп-яшелләнеп үк китте. 5)Туфрак килеште үзенә – бераздан чәчәк тә атты, тәрәзә төбен бизәп, әллә кайдан янып-балкып тора башлады...

6) Минем шатлыгымның иге-чиге булмады. 7)Гөлемнең чәчәкләрен һәр кергән кешегә сокланып, горурланып күрсәтә идем.

8)Кинәт аңа әллә ни булды да куйды. 9)Берничә көн эчендә таҗларын коеп бетереп, гөлем шиңә башлады. 10) Башта яфрак очлары саргайды, аннары сабагы да, сагыштан зар булган кеше төсле, сыгылып

төште...

11)Мин җанымны кая куярга да белмәдем, һаман су сиптем, гөлнең төбен йомшарттым, кояшлырак урынга алып куйдым. 12)Ләкин үсемлеккә болар да файда итмәде.

13)Шунда әниемә дәштем.

14) - Туфрагы килешмәгәндер, улым, туфрагы, туган туфракка ни җитә! - дип, уйчан гына әйтеп куйды ул.

15) "Кеше - табигать баласы" дип юкка гына әйтмиләрдер, күрәсең. 16) Кеше, туган якларыннан аерылып, җиткелеккә ирешсә дә, тулы бәхеткә ия була алмый, үзен һәрчак ятим сизә, моңсулана, боега, шиңә бит... 17)Гөлне урманына илткәндә, шул хакта уйланып бардым.

( Г.Гыйльманнан)

***В өлеше***

***В1-В8 биремнәренукылган текст нигезендәүтәгез. Әлеге биремнәрнең җавабын сүзләр яки цифрлар белән языгыз.***

**В1. 15-17нче җөмләләрдән борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзне язып алыгыз.**

**В2. 8-12 нче җөмләләрдән тамыр + ясагыч кушымча + ясагыч кушымча + бәйләгеч кушымча схемасына туры килгән сүзне язып алыгыз.**

**В3. 6-7 нче җөмләләрдән тартымлы исемнәрне табып языгыз.**

**В4. 10-12 нче җөмләләрдән йөкләтү юнәлешендәге фигыльне язып алыгыз.**

**В5. 6-10 нчы җөмләләрнең кайсысы тезмә кушма җөмлә?**

**В6. 1-3 нче җөмләләрнең кайсысында аерымланган хәл бар?**

**В7.9 нчы җөмләнең грамматик нигезен языгыз.**

**В8. 1-5нче җөмләләрнең кайсысында кире сүз тәртибе күзәтелә?**

**Правильные ответы**

| № | I **вариант җаваплар** |
|---|---|
| А 1 | 2 |
| А2 | 3 |
| А3 | 3 |
| А4 | 2 |
| А5 | 4 |
| А6 | 4 |
| А7 | 1 |
| А8 | 2 |
| А9 | 4 |
| А10 | 3 |
| А11 | 4 |
| А12 | 2 |
| А13 | 1 |
| А14 | 4 |
| А15 | 1 |
| А16 | 1 |
| В1 | Якларыннан |
| В2 | Үсемлеккә |
| В3 | шатлыгымның, иге-чиге, гөлемнең, чәчәкләрен |
| В4 | Йомшарттым |
| В5 | 10 |
| В6 | 2 |
| В7 | Гөлем шиңә башлады |
| В8 | 1 |